ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

КАРАР

«29» апрель 2025 ел Яр Чаллы № 1437

«Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» төбәк проекты кысаларында «2020-2027 елларга Тукай муниципаль районында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» программасын гамәлгә ашыру максатында 2025 елның II кварталына Тукай муниципаль районы буенча гомуми торак мәйданының 1 квадрат метры бәясе нормативын раслау турында

«Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» төбәк проекты кысаларында «2020-2027 елларга Тукай муниципаль районында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» программасын гамәлгә ашыру максатында, «Татарстан Республикасы бәяләүчеләр берләшмәсе» коммерциясез партнерлыгының 2025 елның 14 февралендәге 75 номерлы хаты нигезендә һәм Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының 2025 елның 21 мартындагы 172/пр номерлы боерыгын исәпкә алып,

КАРАР БИРӘ:

1. «Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» төбәк проекты кысаларында «2020-2027 елларга Тукай муниципаль районында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» программасын гамәлгә ашыру кысаларында гражданнарның торак шартларын яхшырту буенча чаралар үткәрүгә социаль түләүләр күләмен исәпләү өчен, 2025 елның II кварталына Тукай муниципаль районы территориясендә гомуми торак мәйданының 1 кв. м бәясен 68000 сум 00 тиен күләмендә расларга.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Тукай муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет Җитәкчесе К.Р. Нәҗмиев